РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.12.2019 № 1678-п

Муниципаль гарантияләр бирүгә бәйле
аерым мәсьәләләр турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115, 1152 һәм 1153 статьялары һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 37 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

– Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе бирелгәндә принципалның финанс хәле анализын, шулай ук Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе бирелгәннән соң принципалның финанс хәле мониторингын гамәлгә ашыру тәртибе;

– Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне, шулай ук Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәннән соң тәэмин ителүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

– Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе буенча принципалга гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибе.

2. Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясенең гамәлдә булу срогы дәвамында гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең җитәрлек булмавы ачыкланганда, (шул исәптән принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә банк гарантиясе яисә җаваплылыкны үз өстенә алуны биргән принципалның, юридик затның финанс хәле шактый начарланган очракта, залог предметының базар бәясе кимегән очракта) принципал тарафыннан 90 көн эчендә тәэмин итү (тулы яки өлешчә) алмаштырыла, яисә, составны һәм гомуми күләмне (сумманы) Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү максатларында, өстәмә (җитмәгән суммага) тәэмин итү бирелә дип билгеләргә.

3. 100 % акцияләре Саба муниципаль районы милкендә булган хуҗалык җәмгыяте булып торучы яисә аның йөкләмәләре буенча Саба муниципаль районы

муниципаль гарантиясе бирелгән һәм милке Саба муниципаль районы милкендә булган муниципаль унитар предприятие (өлеше) булып торучы принципалны тулысынча яки өлешчә хосусыйлаштырган очракта, принципал, хосусыйлаштыру тәмамланган көннән алып 90 көн эчендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1153 статьясы һәм Россия Федерациясе граждан законнары таләпләренә туры килә торган гарантның тулы күләмдә яисә гарантиянең нинди дә булса өлешендә үтәлүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән регресс таләбен канәгатьләндерү буенча үз йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 9 декабрендәге
1678-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә
принципалның финанс хәле анализын,шулай ук
Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясен
биргәннән соң принципалның финанс хәле
мониторингын гамәлгә ашыру Тәртибе

1. Әлеге тәртип Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәлен анализлауны (алга таба – башлангыч анализ), шулай ук Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәннән соң принципалның финанс хәле мониторингын (алга таба – киләсе анализ) гамәлгә ашыруга таләпләрне билгели.

2. Принципалның финанс хәлен алдан анализлау Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан муниципаль гарантия (алга таба – гарантия) бирелгәнче гамәлгә ашырыла.

3. Принципалның финанс хәлен киләсе анализлау гарантия бирү срогы дәвамында гарантия биргәннән соң ел саен гарантия буенча йөкләмәләр туктатылганчы, Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Принципалның финанс хәлен алдан анализлауны гамәлгә ашыру Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган муниципаль гарантия алу өчен принципал тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге буенча бирелә торган документларны анализлау нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Принципалның финанс хәлен анализлау агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмыйча, Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына принципал тарафыннан тапшырыла торган түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган формалар буенча соңгы хисап елында принципал эшчәнлеге турында бухгалтер хисабы күчермәләре һәм аларга территориаль салым органы тамгалары белән аңлатма язмалары (яисә аларны электрон рәвештә кабул итү турында территориаль салым органына хәбәр итү);

иң зур дебиторларны һәм кредиторларны (гомуми бурычның биш проценттан артыгын) һәм аны түләү срокларын күрсәтеп, агымдагы ел башына һәм агымдагы елның соңгы хисап чоры ахырына дебитор һәм кредит бурычларын расшифровкалау;

хисап елы өчен принципалның бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында аудиторлык бәяләмәсенең нотариаль расланган күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри еллык аудиторлык тикшерүе үткәрелергә тиешле икътисадый субъектларга кагыла);

салым органының барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча принципалның бурычы булмау турында аны тапшыру датасына кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча алынган белешмәләре;

соңгы хисап датасына һәм агымдагы ел башына принципалның чиста активлары бәясен исәпләү.

6. Принципалның финанс хәлен бәяләү әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә финанс күрсәткечләре нигезендә үткәрелә.

7. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан принципалның финанс хәлен алдан һәм аннан соңгы анализлау нәтиҗәләре буенча тиешле бәяләмәләр төзелә.

8. Принципалның финанс хәлен анализлау, аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзү һәм бәяләмәне Саба муниципаль районының Башкарма комитетына бирү принципал тарафыннан әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документлар тапшырылганнан соң 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе бирелгәндә принципалның финанс хәле анализын гамәлгә ашыру, шулай ук Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе тапшырылганнан соң принципалның финанс хәле мониторингын гамәлгә ашыру тәртибенә Кушымта

**Принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы**

1.1. Принципалның финанс хәлен бәяләү өчен бухгалтерлык балансы һәм финанс нәтиҗәләре турындагы хисап белешмәләре нигезендә исәпләнелә торган төп финанс индикаторларының өч төркеме кулланыла:

ликвидлык коэффициентлары;

үз һәм заем акчалары нисбәте коэффициенты;

рентабельлек күрсәткече.

2. Ликвидлык коэффициентлары.

2.1. Ликвидалык коэффициентлары төркеме өч күрсәткечтән тора:

абсолют ликвидлык коэффициенты;

тиз ликвидлык коэффициенты;

агымдагы ликвидлык коэффициенты.

2.2. Абсолют ликвидлык коэффициенты (К1) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_1 = \frac{ден.средства(1250) + кр.фин.вложения(1240)}{тек.обязательсва(1500 - 1530 - 1540)},$$

Монда:

акчалар(1250) – кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акчалар (бухгалтерлык балансының юл коды 1250),

кыска сроклы финанс кертемнәре(1240) – хисап чоры ахырына исәпләнгән кыска сроклы финанс чыгымнары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ. б.) суммасы (бухгалтерлык балансының юл коды 1240),

агымдагы йөкләмәләр(1500-1530-1540) – хисап датасыннан соң 12 айдан азрак вакыт эчендә түләнә торган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Кыйммәте V бухгалтерлык балансы бүлеге (бухгалтерлык балансының 1500 юл коды), булачак чор керемнәре (бухгалтерлык балансының 1530 юл коды) һәм бәяләү йөкләмәләре (бухгалтерлык балансының 1540 юл коды) нәтиҗәсенең аермасы буларак карала.

2.3. Тиз ликвидлык коэффициенты (К2) хуҗалык әйләнешеннән акчаларны оператив төстә чыгару һәм булган финанс йөкләмәләрен каплау мөмкинлеген характерлый. Күрсәткеч түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_2 = \frac{деб.задолженность(1230) + кр.фин.вложения(1240) + ден.средства(1250)}{тек.обязательства(1500 - 1530 - 1540)},$$

Монда

дебиторлык бурычы (1230) - ел дәвамында түләнүе көтелә торган дебиторлык бурычы (бухгалтерлык балансының юл коды 1230),

Кыска сроклы финанс кертемнәре - хисап чоры ахырына кадәр формалашкан кыска сроклы финанс кертемнәре суммасы (акцияләр, вексельләр, заемнар бирелгән облигацияләр һ.б.). (бухгалтерлык балансының юл коды 1240),

акчалар - кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акчалар (бухгалтерлык балансының юл коды 1250),

агымдагы йөкләмәләр(1500-1530-1540) – хисап датасыннан соң 12 айдан азрак вакыт эчендә түләнә торган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Кыйммәте V бухгалтерлык балансы бүлеге (бухгалтерлык балансының 1500 юл коды), булачак чор керемнәре (бухгалтерлык балансының 1530 юл коды) һәм бәяләү йөкләмәләре (бухгалтерлык балансының 1540 юл коды) нәтиҗәсенең аермасы буларак карала.

2.4. Агымдагы ликвидлык коэффициенты (К3) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_3 = \frac{\textit{оборотн.активы}(1200)}{\textit{крат.обязательства}(1500-1530)},$$

Монда

әйләнеш активлары (1200) - әйләнеш активлары (бухгалтерлык балансының 1200 юл коды),

кыска сроклы йөкләмәләр (1500-1530) - кыска сроклы финанс йөкләмәләре, хисап датасыннан соң 12 айдан да кимрәк булган вакыт эчендә түләнә торган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Кыйммәте V бухгалтерлык балансы бүлеге (бухгалтерлык балансының 1500 юл коды) һәм киләчәк чорлар керемнәре (бухгалтерлык балансының 1530 юл коды) нәтиҗәсенең аермасы буларак тора.

3. Үз һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты.

3.1. Үз һәм заем чараларының нисбәте коэффициенты (К4) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_4 = \frac{\textit{собственный капитал}(1300)}{\textit{заемный капитал}(1500+1400-1530)},$$

Монда

үз капиталы (1300) - үз капиталы һәм резервлары (бухгалтерлык балансының 1300 юл коды),

заем капиталы (1500 1400-1530) - финанс йөкләмәләре. Кыйммәте, булачак чорларның керемнәрен исәпкә алмыйча (бухгалтерлык балансының 1500 һәм 1400 юл кодлары), кыска сроклы һәм озак сроклы йөкләмәләр суммасы буларак тора (бухгалтерлык балансының 1530 юл коды).

4. Рентабельлек күрсәткече

4.1. Рентабельлек күрсәткечен исәпләү процедурасы (К5) сәүдә һәм башка предприятиеләр өчен аерыла.

4.2. Сәүдә предприятиеләре өчен рентабельлек күрсәткече продукциянең рентабельлегенең финанс коэффициенты нигезендә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_5 = \frac{\textit{прибыль от продаж}(2200)}{\textit{валовая прибыль}(2100)},$$

Монда

сатудан кергән табыш (2200) - продукцияне сатудан кергән табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2200 юл коды),

тулаем табыш (2100) - тулаем табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2100 юл коды).

4.3. Сәүдә белән шөгыльләнмәгән предприятиеләр өчен рентабельлек күрсәткече төп эшчәнлек рентабельлегенең финанс коэффициенты белән тәңгәл килә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_5 = \frac{прибыль\ от\ продаж(2200)}{выручка(2110)},$$

Монда

сатудан кергән табыш (2200) - продукцияне сатудан кергән табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2200 юл коды),

керем (2110) – сатудан кергән керем (финанс нәтиҗәләре турындагы хисапның 2110 юл коды).

5. Финанс хәлен бәяләүнең төзелеше.

5.1. Һәр база индикаторы өчен иң яхшы һәм иң начар кыйммәтләр билгеләнә.

5.2. Алынган кыйммәт һәм чик кыйммәтләр нигезендә һәр күрсәткеч өчен өч категориянең берсе билгеләнә. Күрсәткечләрнең чик кыйммәтләре һәм категорияне сайлау кагыйдәсе, күрсәткечләрнең факттагы кыйммәтләренә карап, 1 таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица. Күрсәткечләрнең чик кыйммәтләре һәм күрсәткечләрнең факттагы кыйммәтләренә карап категория сайлау.

| Коэффициентлар | 1 категория (күрсәткечнең яхшы кыйммәте) | 2 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек кыйммәте) | 3 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек булмаган кыйммәте ) |
|---|---|---|---|
| $K_1$ | 0,2 дән күбрәк | 0,1 – 0,2 | 0,1 дән кимрәк |
| $K_2$ | 0,8 дән күбрәк | 0,5 – 0,8 | 0,5 тән кимрәк |
| $K_3$ | 2,0 дән күбрәк | 1,0 – 2,0 | 1,0 дән кимрәк |
| $K_4$ | | | |
| Сәүдә предприятиеләре | 0,6 дан күбрәк | 0,4 – 0,6 | 0,4 тән кимрәк |
| Башка тармак предприятиеләре | 1,0 дән күбрәк | 0,7 – 1,0 | 0,7 дән кимрәк |
| $K_5$ | 0,15 тән күбрәк | 0,0 – 0,15 | 0,0 дән кимрәк (рентабель түгел) |

5.3. Җыелма бәяләүнең (S) әһәмияте түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S = Вес_1 \times Категория_1 + Вес_2 \times Категория_2 + Вес_3 \times Категория_3 + \\ + Вес_4 \times Категория_4 + Вес_5 \times Категория_5,$$

Монда

Авырлык $_i$ - җыелма бәяләүдә Ki күрсәткеченең авырлыгы, i=1, 2, 3, 4 яки 5. Авырлык кыйммәтләре 2 таблицада тәкъдим ителгән.

Категория $_i$ – $K_i$ күрсәткеченең кыйммәте карый торган категория.

Категория$_i$ = 1, 2 яки 3.

2 Таблица. Җыелма бәяләүне исәпләгәндә кулланыла торган күрсәткечләрнең авырлыгы.

| Күрсәткеч | Күрсәткеч авырлыгы |
|---|---|
| Абсолют ликвидлык коэффициенты (К1) | 0,11 |
| Тиз ликвидлык коэффициенты (К2) | 0,05 |
| Агымдагы ликвидлык коэффициенты (К3) | 0,42 |
| Үз һәм заем акчаларының нисбәте (К4) | 0,21 |
| Рентабельлек коэффициенты (К5) | 0,21 |

5.4. Җыелма бәяләүнең кыйммәте нигезендә принципалның финанс хәле дәрәҗәсе билгеләнә.

Принципалның финанс хәле түбәндәге дәрәҗәләрнең берсенә ия булырга мөмкин:

җыелма бәяләүнең күрсәткече 1,05 тан артмаса, финанс хәленең дәрәҗәсе яхшы була;

җыелма бәяләүнең күрсәткече 1,05 тән зуррак булса, әмма 2,4 тән артмаса, финанс хәленең дәрәҗәсе канәгатьләнерлек була;

җыелма бәяләүнең кыйммәте 2,4 тән артса, финанс хәленең дәрәҗәсе канәгатьләнерлек булмый.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 9 декабрендәге
1678-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерү,шулай ук Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәннән соң тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшереп торуны гамәлгә ашыру Тәртибе**

1. Әлеге тәртип Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне, шулай ук Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәннән соң тәэмин ителүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшереп торуны гамәлгә ашыруга таләпләрне билгели;

2. Тулы күләмдә яисә гарантиянең нинди дә булса өлешендә гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү сыйфатында түбәндәге тәэмин итүнең бер яисә берничә төре кабул ителергә мөмкин:

- дәүләт яки муниципаль гарантия;
- юридик затның җаваплылыкны үз өстенә алуы ;
- гарантия белән тәэмин ителә кредит буенча принципалның кредиторы булып тормаган кредит оешмасының банк гарантиясе;
- принципал яисә өченче зат милкен залогка салу.

3. Саба муниципаль районы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычлары һәм Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законы нигезендә түләнергә тиешле салым, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булган,шулай ук чиста активлары бәясе бирелгән банк гарантиясенең (бирелгән җаваплылыкны үз өстенә алуның) өч тапкыр суммасын тәшкил иткән зурлыктан азрак булган юридик затларның банк гарантияләре һәм җаваплылыкны үз өстенә алуын,бөлгенлеккә (банкротлык) төшүе турында эш кузгатылган юридик затларны,үзгәртеп кору яки юкка чыгу процессында булган юридик затларны йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү сыйфатында кабул итү рөхсәт ителми.

4. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшерү Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гарантия бирелгәнче, шулай ук гарантия бирелгәннән соң, гарантия срогы дәвамында гарантия буенча йөкләмәләр туктатылганчы ел саен 1 июньнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

5. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшерүне гамәлгә ашыру, принципал тарафыннан Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясен алу өчен тапшырылырга тиешле документлар исемлеге буенча тапшырыла торган документларны анализлау нигезендә һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясен бирү турында шартнамә төзү нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын тикшерү, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе буенча принципалга гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибендә каралган тәртиптә, бирелә торган (бирелгән) тәэминатның гарантның гарантия буенча принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләменә (суммасына) туры килүен билгеләүдән гыйбарәт.

7. Банк гарантиясе һәм җаваплылыкны үз өстенә алуның ышанычлылыгы банк яки башка кредит оешмасының (алга таба – банк-гарант) һәм җаваплылыкны үз өстенә алучының финанс хәле тотрыклылыгы белән билгеләнә.

8. Банк-гарант бер үк вакытта түбәндәге таләпләргә туры килсә, банк-гарантның финанс хәле тотрыклы дип һәм банк гарантиясе ышанычлы дип таныла:

а) банк операцияләрен гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясе булу;

б) “Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен иминләштерү турында” 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен мәҗбүри иминләштерү системасында кредит оешмасының катнашуы;

в) I, II категорияле активлар күләменең активларның гомуми күләменең кимендә 50 проценты зурлыгында булуы;

г) кредит оешмасының кимендә 1 млрд. сум күләмендә үз акчалары (капиталы) булуы.;

д) мәҗбүри нормативларны үтәү буенча Россия Федерациясе Үзәк банкы таләпләрен үтәү (шул исәптән банк гарантиясе бирүгә бәйле рәвештә кабул ителә торган бурыч йөкләнешен исәпкә алып);

е) агымдагы елның соңгы хисап елы һәм соңгы хисап чорында эшчәнлек нәтиҗәләре буенча югалтулар булмау;

ж) кредит рейтинг агентлыгы аналитик кредит рейтинг агентлыгы (акционерлык җәмгыяте) Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча “A-(RU)” дәрәҗәсеннән ким булмаган, Россия Федерациясе өчен кредит рейтинг агентлыгы буенча “Эксперт РА “рейтинг агентлыгы” акционерлык җәмгыяте өчен милли рейтинг шкаласы буенча “ruA –“ дәрәҗәсеннән ким булмаган , яисә “Standard & Poor 's” яки “Fitch Ratings” рейтинг агентлыклары классификациясе буенча “BB –“ рейтингыннан ким булмаган яисә “Moody' s” рейтинг агентлыгы классификациясе буенча “Вв – “рейтингыннан ким булмаган кредит рейтингы булу.

9. Җаваплылыкны өстенә алучының финанс хәлен бәяләү, принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә, Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәлен анализлауны гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта булып торучы принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә,шулай ук Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе тапшырылганнан соң принципалның финанс хәлен мониторинглау нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Җаваплылыкны үз өстенә алучының финанс хәле яхшы яисә канәгатьләнерлек дәрәҗәдә бәяләнсә, шулай ук җаваплылыкны үз өстенә алучының кредит рейтинг агентлыгы аналитик кредит рейтинг агентлыгы (акционерлык җәмгыяте) Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча “A-(RU)” дәрәҗәсеннән ким булмаган, Россия Федерациясе өчен кредит рейтинг агентлыгы буенча “Эксперт РА “рейтинг агентлыгы” акционерлык җәмгыяте өчен милли рейтинг шкаласы буенча “ruA –“ дәрәҗәсеннән ким булмаган , яисә “Standard & Poor 's” яки “Fitch Ratings” рейтинг агентлыклары классификациясе буенча “BB –“ рейтингыннан ким булмаган яисә “Moody' s” рейтинг агентлыгы классификациясе буенча “Вв –

“рейтингыннан ким булмаган кредит рейтингы булса, җаваплылыкны үз өстенә алучының финанс хәле тотрыклы һәм җаваплылыкны үз өстенә алу ышанычлы дип таныла.

11. Принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен тәэмин итүгә принципал яисә өченче зат тарафыннан залогка бирелә торган (бирелгән) мөлкәтне бәяләү һәм әлеге мөлкәтнең ликвидацияләү дәрәҗәсен билгеләү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 932 статьясындагы 3 пунктының җиденче абзацы нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы, тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшергәннән соң 10 көн эчендә Саба муниципаль районы Башкарма комитетына тиешле бәяләмә бирә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 2 декабрендәге
1627-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе буенча гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәндә принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципалның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләменә (суммасына) карата, шулай ук Саба муниципаль районының муниципаль гарантиясенең гамәлдә булу срогы дәвамында таләпләрне билгели.

2. Гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләме (суммасы), Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә, принципалның финанс хәлен анализлау тәртибенә кушымта булып торучы принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә ачыклана торган аның финанс хәленең канәгатьләнерлек дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, шулай ук Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясе тапшырылганнан соң принципалның финанс хәлен мониторинглау нигезендә билгеләнә.

3. Минималь тәэмин итү күләме :

принципалның финанс хәле яхшы булганда Саба муниципаль районы муниципаль гарантия суммасының 100 проценты дәрәҗәсенә;

принципалның финанс хәле дәрәҗәсе канәгатьләнерлек дәрәҗәдән югары булмаганда Саба муниципаль районының муниципаль гарантия суммасының 120 проценты дәрәҗәсенә туры килә.

4. Саба муниципаль районы муниципаль гарантиясенең принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең гомуми күләменең (суммасының) минималь тәэмин итү күләменә туры килүен бәяләү:

юридик затларның җаваплылыкны үз өстенә алулары, банк гарантияләре, дәүләт (муниципаль) гарантияләре алар бирелгән суммада исәпкә алына;

бәяләве Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясындагы 3 пунктының җиденче абзацы нигезендә гамәлгә ашырыла торган залогка тапшырыла (тапшырылган) торган мөлкәтнең базар бәясенә 0,7 коэффициентын кулланып төзәтмәләр кертелергә тиеш.